# БӘЯЛӘМӘ

**1. Казан шәһәре 34 нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы Гимадеева Нурия Рәшит кызы**

**2. Авторлык программасы**

| **Исеме (темасы)** | **"Туган телем – заман теле"** |
|---|---|
| **Инновациянең формасы** *(астына сызарга яисә язып бетерергә)* | Авторлык программасы |
| **Инновациянең кыскача эчтәлеге** | Курс укучыларга гуманитар профильгә юнәлеш бирә һәм бердәм республика тестына әзерләү курсы булып тора. Ул укучыларны мәктәп программасына кертелгән теоретик материалларны кабатлау, бердәм республика тесты кагыйдәләре һәм таләпләре белән таныштыруга юнәлтелгән |
| **Инновациянең яңалыгы** | Традицион практиканы камилләштерә |
| **Куллану масштабы (дәрәҗәсе)** | Аерым педагог һәм белем бирү учреждениесе дәрәҗәсендә |
| **Инновациянең әһәмияте** | Бу курсны индивидуаль дә, республика күләмендә дә кулланып була |
| **Инновациянең үсеш этабы (стадиясе)** | Курс программасы укыту процессында кулланыла |
| **Ирешелгән нәтиҗә** | Тел күренешләрен анализлый, төркемли белү, тел берәмлекләрен төгәл сайлый, дөрес файдалана белү, төрле фукциональ стильгә һәм функциональ текстларга лингвистик анализ ясый алу, максатка яраклаштырып, үз сөйләмен оештыра белү, сөйләмен үзлектән тикшерә белү |
| **Белем бирү системасының структур элементларына мөнәсәбәтле рәвештә инновациянең тибы** | Максат, бурычлар яңалыгы; **белем бирүнең эчтәлеге,** тәрбия бирү, идарә итү; **формаларда, методларда, алымнарда, чараларда яңалык**, белем һәм тәрбия бирү технологияләре өлкәсендә; **диагностика өлкәсендә, контроль**, нәтиҗәләр бәясендә һ.б. *(Астына сызарга һәм язып бетерергә)* |
| **Укучының шәхес булып формалашуга мөнәсәбәтле рәвештә** | Укучыларны бердәм республика тестын бирүгә әзер булуына ирешү |
| **Куллану өлкәсе буенча** | Укыту процессында, белем бирүдә |
| **Педагогик процесста катнашучыларның үзара мөнәсәбәт типлары буенча** | Коллектив укыту системасында |

**III. Хезмәтнең өстенлеге**

**"Туган телем – заман теле"** факультатив курсының авторлык программасы 34 сәгатькә исәпләнгән. Ул 9 нчы сыйныфның татар төркемендә укучылар өчен татар теленнән бердәм республика тестына әзерләү курсы буларак тәкъдим ителә.

Программаның сайлап алынган темасы актуаль, чөнки бу курс укучыларны мәктәп программасына кертелгән материалларны өйрәнү, кабатлауны гына түгел, ә бәлки, беренче чиратта, гуманитар профильгә юнәлеш биреп, бердәм республика тестына әзерләүне максат итеп куя. Программада тәкъдим ителгән темалар, эш төрләре укучылар өчен файдалы. Алар иҗади эзләнергә, фикерләргә өйрәтә; туган телнең үзенчәлекләрен аңларга өйрәтә.

Кушымтада дәрес үрнәкләре тәкъдим ителүе уңышлы. Алардагы биремнәр логик эзлеклелектә, укучыларның яшь үзенчәлекләре исәпкә алынып төзелгәннәр. Хезмәт күләмле, авторның бу мәсьәләдә шактый эшләгәне сизелеп тора.

**IV. Хезмәтнең җитешсезлеге**

-

**V. Тәкъдимнәр.**

Әдәбият исемлеген ГОСТ таләпләренә туры китереп эшләргә кирәк.

**VI. Нәтиҗәләр.**

Гимадеева Нурия Рәшит кызының "Туган телем – заман теле" хезмәте авторлык программаларына куела торган төп таләпләргә туры килә һәм аны уку-укыту эшчәнлегенә кертергә мөмкин.

**Рецензент** Мөхәрләмова Гөлназ Нурфатовна________________

Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясе Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының татар телен һәм әдәбиятын укытуның хәзерге көн проблемалары бүлегенең өлкән фәнни хезмәткәре

СОБСТВЕННУЮ ПОДПИСЬ Мухарлямовой Г.Н. ЗАВЕРЯЮ:
УЧЕНЫЙ СЕКРЕТАРЬ ИНСТИТУТА ЯЗЫКА, ЛИТЕРАТУРЫ И ИСКУССТВА ИМЕНИ Г.ИБРАГИМОВА АН РТ

17.10. 2017

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ КАЗАН ШӘҺӘРЕ Г.ИБРАҺИМОВ исемендәге ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ
КАНЦЕЛЯРИЯ
АКАДЕМИЯ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН г.КАЗАНЬ ИНСТИТУТ ЯЗЫКА, ЛИТЕРАТУРЫ И ИСКУССТВА имени Г.ИБРАГИМОВА